**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүне камилләштерү һәм аларны һөнәри хезмәт эшчәнлегенә кызыксындыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2024 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы, 2018 елның 4 августындагы ПУ-550 номерлы, 2019 елның 13 августындагы ПУ-466 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге ПУ-73 номерлы, 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-664 номерлы, 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы, 2023 елның 12 гыйнварындагы ПУ-10 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 маендагы 333 номерлы, 2023 елның 13 июлендәге 490 номерлы, 2023 елның 22 августындагы 575 номерлы һәм 2023 елның 2 декабрендәге 828 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи окладлары турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-242 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 15 октябрендәге ПУ-697 номерлы, 2021 елның 12 июлендәге ПУ-565 номерлы, 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 15 мартындагы 162 номерлы һәм 2023 елның 23 декабрендәге 902 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында» 2020 елның 15 августындагы ПУ-498 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру турында» 2022 елның 19 августындагы ПУ-575 номерлы һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-664 номерлы указлары белән билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең алар биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына туры килгән айлык окладлары (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары) күләмен арттырырга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен әлеге Указның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары территориаль органнарының кече төркем вазыйфалары «тәэмин итүче белгечләр» категориясе 3 разрядлы белгеченең вазыйфаи окладь күләмен 1,05 тапкырга индексацияләргә һәм ул 13 323 сум тәшкил итәчәк.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» 2018 елның 22 мартындагы ПУ-239 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 3 маендагы ПУ-347 номерлы, 2018 елның 4 августындагы ПУ-550 номерлы, 2019 елның 13 августындагы ПУ-466 номерлы, 2021 елның 1 февралендәге ПУ-73 номерлы, 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-664 номерлы, 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы, 2023 елның 12 гыйнварындагы ПУ-10 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 25 маендагы 333 номерлы, 2023 елның 13 июлендәге 490 номерлы, 2023 елның 22 августындагы 575 номерлы һәм 2023 елның 2 декабрендәге 828 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 пунктның 6 пунктчасындагы «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктның 6 пунктчасындагы «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

5. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә элек чыгарылган актларын әлеге Указга туры китерергә.

6. Әлеге Указ 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 10 май
№ 335